| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Новоимянского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Яна Имэн авыл җирлеге<br>советы |

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**14 ноябрь 2020 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Күтәмәле авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Күтәмәле авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Күтәмәле авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);
- җәйге чорда территорияне чабу, урып-җыю (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- «Беларус-82,1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
- Күтәмәле авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Күтәмәле авылы Пушкин ур. буенча җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- Күтәмәле авылы зираты өчен генератор сатып алу;
- Күтәмәле авылы аншлагларын әзерләү һәм алыштыру;
- бәйрәмнәр үткәрү өчен , бүләкләр алу (Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне);

3. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р. Ф.Гараев